| | |
|---|---|
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>*БУА ШӘҺӘРЕ*<br>*БУА*<br>*МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*<br>*БАШЛЫГЫ* | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>*ГЛАВА*<br>*ГОРОДА БУИНСКА*<br>*БУИНСКОГО*<br>*МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА* |

КАРАР
ПОСТАНОВЛЕНИЕ

« 16 » май 2020 ел 2нче номерлы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре», «Татар Буасы авыл җирлеге», «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» һәм «Ырыңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» 2020 елның 15 маендагы 3-53 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карары нигезендә, Буа шәһәрендә яшәүчеләрнең хокукларын үтәү максатында Буа шәһәре муниципаль берәмлеге чикләре турындагы проект буенча фикер алышуда гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән катнашу максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татар Буасы, Түбән Наратбаш һәм Ырынгы авыл җирлекләре чикләренә керүче җир кишәрлекләрен кертү юлы белән «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрүне 2020 елның 16 июненә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Буа шәһәре, Р. Люксембург урамы, 65 нче йорт адресы буенча Ял үзәге бинасына билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларда фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2020 елның 15 июненә кадәр Буа шәһәре, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты, Жорес урамы, 110А йорт, 9 каб. адресы буенча кабул ителә, телефон 3-11-93

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча һәм Буа шәһәренең мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

- ТР, Буа шәһәре, Жорес ур., 110А (Буа муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы);
- ТР, Буа шәһәре, Космовский ур., 91Б (Буа шәһәре Башкарма комитеты бинасы);
- ТР, Буа шәһәре, Р. Люксембург ур., 157 (район мәдәният йорты бинасы);
- ТР, Буа шәһәре, Төзелеш ур., 4 ( «Сахарник» клуб бинасы).

4. Әлеге карарга кушымта нигезендә, Татар Буасы, Түбән Наратбаш һәм Ырынгы авыл җирлекләре чикләренә керүче җир кишәрлекләрен «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенә кертү юлы белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре», «Татар Буасы авыл җирлеге», «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» һәм «Ырынгы

авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар әзерләү һәм уздыру буенча эшче төркем составын расларга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының
Буа шәһәре башлыгы урынбасары С.А.Зайцева